ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Җир асты байлыклары турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 26 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Җир асты байлыклары турында” 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (1999 елның 6 декабрендәге 2486 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 2 (2); 2001, № 12; 2004, № 7 (I өлеш); 2005, № 4 (I өлеш); 2008, № 3; 2009, № 9 – 10; 2012, № 1, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 4, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 14 статьяның беренче өлешендәге өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“файдалы казылмалар разведкалау һәм чыгару, шул исәптән тау эшләре калдыкларыннан һәм аларга бәйле эшкәртү производстволарыннан файдалану, шулай ук углеводород чималын разведкалау һәм чыгару очрагында тау токымнары катламнарында ияреп чыгучы суларны һәм җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның үзләренең җитештерү, технологик ихтыяҗлары өчен файдаланган суларны урнаштыру;”;

2) 15 статьяның өченче өлешендә “нефть һәм газ саклагычлар төзү һәм эксплуатацияләү өчен,” сүзләреннән соң “углеводород чималын разведкалаганда һәм чыгарганда тау токымнары катламнарында ияреп чыгучы суларны һәм җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның үзләренең җитештерү, технологик ихтыяҗлары өчен файдаланган суларны урнаштыру өчен,” сүзләрен өстәргә;

3) 18 статьяда түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“тау эшләнмәләрен бетерү өчен капкач токымнардан һәм сыйдырышлы тау токымнарыннан, кара металлар җитештерүнең куркынычлылык дәрәҗәсе IV һәм V класс булган калдыкларыннан файдаланырга.”;

4) 19 статьяның беренче өлешендә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“тау токымнары катламнарында ияреп чыгучы суларны һәм җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның үзләренең җитештерү, технологик ихтыяҗлары өчен файдаланган суларны урнаштырганда әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясауга юл куймауны.”;

5) 73 статьяның тугызынчы абзацында “чыгарганда” сүзеннән соң “, тау токымнары катламнарында ияреп чыгучы суларны һәм җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның үзләренең җитештерү, технологик ихтыяҗлары өчен файдаланган суларны урнаштырганда” сүзләрен өстәргә;

6) 91 статьяның өченче өлешендә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Тау эшләнмәләрен бетерү өчен капкач токымнардан һәм сыйдырышлы тау токымнарыннан, кара металлар җитештерүнең куркынычлылык дәрәҗәсе IV һәм V класс булган калдыкларыннан тау эшләнмәләрен бетерү проекты нигезендә файдаланырга мөмкин.”.

**2 статья**

Әлеге Закон 2015 елның 1 февраленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2014 елның 15 декабре
№ 119-ТРЗ